Утверждаю
заместитель председателя
Общественного Совета Азнакаевского
муниципального района
___________Л.М. Ахмадишина

# ПРОТОКОЛ № 9
## расширенного заседания Общественного Совета Азнакаевского муниципального района

г. Азнакаево «28» февраля 2017 года
Зал заседаний райсовета 10.00 час.

Повестка дня

1. Вступительное слово.
2. Реализация концепции национальной политики в АМР.
3. Азнакай муниципаль районында милли мәгарифнең үсеше.
4. Основные направления государственной политики в области преподавания языков.
5. Гимназия шартларында укучыларда милли үзаң тәрбияләү.
6. Взаимодействие институтов гражданского общества по сохранению традиций.
7. Развитие чувашской национальной культуры в АМР.
8. Выбор делегатов Съезда народов Татарстана.
9. Заслушивание решения оптимизационной комиссии Азнакаевской центральной районной больницы.

Выступали:

1. Ахмадишина Лилия Мугамбаровна – Член Общественной Палаты РТ, заместитель председателя Общественного Совета Азнакаевского муниципального района.
2. Роджерс Альбина Агдасовна - Секретарь Комиссии по языкам, методист Управления образования.
3. Абдуллина Дилярия Маратовна - ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова Академии наук РТ, автор учебников по татарской литературе, автор новой Концепции преподавания татарского языка и литературы, кандидат филологических наук.
4. Рахманов Альберт Магалимович - Член Общественного Совета, председатель Совета директоров школ.

5. Галиева Эльвира Сайлуновна - председатель общественной организации татарских женщин «Ак калфак», начальник организационного отдела районного Совета.

6. Владимиров Олег Иванович - Председатель местного отделения Чувашской национально-культурной автономии.

7. Халиуллин Айдар Фандасович – руководитель аппарата районного Совета

8. Шигапов Ильдар Фираилевич – главный врач ГАУЗ «Азнакаевская ЦРБ».

*Председательствуют:* ***Шайдуллин Марсель Зуфарович*** *– Глава Азнакаевского муниципального района.* ***Ахмадишина Лилия Мугамбаровна*** *- Член Общественной Палаты РТ, заместитель председателя Общественного Совета Азнакаевского муниципального района.*

На расширенном заседании Общественного Совета приняли участие Абдуллина Дилярия Маратовна - ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ, автор учебников по татарской литературе, автор новой Концепции преподавания татарского языка и литературы, кандидат филологических наук, представители общественных организаций, бюджетных учреждений, предприятий, представители средств массовой информации.

*Вступительное слово:* ***Шайдуллин Марсель Зуфарович*** *– Глава Азнакаевского муниципального района.*

1. Хэерле кон, хормэтле кунаклар, район ижтимагый оешмасы агъзэлэре !

Добрый день, участники расширенного заседания Общественного совета Азнакаевского района! На заседании Общественного совета

Хөрмәтле коллегалар! Белгәнегезчә безнең Азнакай районы адресына Республикабыз Дәүләт Кицәшчесе Минтимер Шәрипович Шәймиев тарафыннан татар теле үсеше һәм кулланылышы буенча тәнкыйть сүзләре белдерелде. Бу хакта район Советында 2016 ел нәтиҗәләре буенча ясалган чыгышымда да тукталып уздым, Хөкүмәт җитәкчесе Илдар Шәфкатович Халиков та әлеге тәнкыйтьнең урынлы булуын һәм районда укыту тәрбия учреждениеләрендә, идарә итү оешмаларында татар телен куллануга аерым игътибар кирәклегенә басым ясады. Республиканың фән һәм мәгариф министрлыгы да килеп туган хәлне үзгәртүгә үзенец тәкъдимнәрен кертте,

махсус программа әзерләнде. Шәһәр һәм район мәктәпләрендә татар телен укытуга, баларда сөйләм телен булдыруга, гореф-гадәтләрне өйрәнүгә педагоглар тарафыннана да, эти-әниләр тарафыннан да аерым игътибар булырга тиеш!

Бүгенге очрашуның төп юнәлеше дә милли телебезне саклау һәм үстерүгә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүгә һәм районыбызда яшәүче башка милләт вәкилләренең әлеге проблемага кагылышлы булган сорауларын ачыклауга нигезләнгән.

Эш барышында актив катнашуыгызны телибез һәм куелган мәсьәләне хәл итү юнәлешендә үзегезнең эшлекле тәкъдимнәрегезне, теләкләрегезне көтеп калабыз.

Хәзер сүзне Иҗтимагый Совет рәисе урынбасары һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы агъзәсе **Әхмәдишина Лилия Мөгамбәровнага** бирәбез.

***(заседание продолжила Ахмадишина Лилия Мугамбаровна)***

В состав общественного совета района включены руководители национально - культурных и религиозных объединений. В вопросах национального развития ОС сотрудничает с Духовным управлением мусульман, Татарстанской митрополией Русской православной церкви, национально-культурными автономиями, землячествами, правоохранительными органами, СМИ, некоммерческими организациями.

На заседаниях Совета Азнакаевского района и общественного совета регулярно рассматриваются вопросы межнациональных и межконфессиональных отношений, а также вопросы по работе с мигрантами.

- «О проведении социологических исследований по гармонизации межэтнических отношений»;
- «Об организации и проведении праздничных мероприятий: «Фольклорный фестиваль тюркских народов «Чатыр тауда жыен»;
- «О проведении традиционных религиозных праздников: «Рождество христово», «Пасха», «Ураза байрам», «Курбан Байрам»»;
- «О проведении мероприятий в рамках сотрудничества с городами-побратимами Тарсус (Турция) и Ивье (Республика Беларусь);
- «О поведении праздника «Иван Купала»», «О проведении Дня родного языка (26 апреля).

Совместно с управлением образования состоялось широкое обсуждение стратегии 2030 и Концепции национальной политики РТ.

Перед нами поставлены задачи по развитию сети национальных образовательных организаций, совершенствованию методического

комплекса и проведению современных культурно-познавательных мероприятий на родных языках.

1. Слушали «Азнакай муниципаль районында милли мәгарифнең үсеше».

Выступила Роджерс Альбина Агдасовна - Секретарь Комиссии по языкам, методист Управления образования.

Районыбыздагы милли мәгариф үсешенең юл картасын тәкъдим итәр алдыннан, иң элек сезне Азнакай районы милли мәгарифенең статистик мәгълүматлары белән таныштырып китәргә рөхсәт итегез.

2016-2017нче уку елында Азнакай муниципаль районы мәктәпләрендә белем алучы укучылар саны 6353 (алты мең оч йөз илле өч) кешене тәшкил итә.(слайд)

Районыбызда барлыгы 23 (егерме өч) гомуми белем бирү оешмасы эшләп килә, шуларның унбере татар телендә белем бирү мәктәпләре булып исәпләнелә. Боларга түбәндәгеләр керә: Азнакай шәһәре гимназиясе, Актүбә бистәсенең өченче мәктәбе һәм “Победа” гомуми белем бирү учреждениесеннән кала барлык авыл мәктәпләре .

Болардан тыш, биш гомуми белем бирү оешмаларының Татшуган, Илбәк, Карамалы, Стәрле, Уразай, Мәлбәгыш, Әлкәй авылларында филиаллар эшли. Җиде рус телле гомуми белем бирү оешмаларында барлыгы тугыз сыйныфта 150 укучы татар телендә белем ала.(слайд)

Район буенча ана телендә белем алучы татар балаларының өлеше егерме биш бөтен йөздән җиде процент тәшкил итсә, шәһәр буенча ул тугыз процентны тәшкил итә.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә барлыгы дүрт мең бер йөз кырык алты бала тәрбияләнә.(слайд)

Районда барлыгы илле биш балалар бакчасы, шуларның егерме бише рус һәм татар телле булса, утызы татар телле. Шулай ук егерме биш рус-татар телле бакчаларда барлыгы 24 татар телле төркемнәр эшләп килә.

Шәһәребездәге дүрт балалар бакчасы татарча белем һәм тәрбия бирә. Боларга өченче номерлы “Айсылу”, тугызынчы номерлы “Салават күпере”, унынчы номерлы “Алтынчәч”, унҗиденче номерлы “Аккош” балалар бакчалары керә.

Барлыгы 2868 (ике мең сигез йөз алтмыш сиге) татар баласының (94,2%) 1034 ( мең дә утыз дүрте) (36%) татар телендә белем ала.

Актүбә бистәсендә бүгенге көндә татар балалар бакчалары булмау проблемасы яшәп килә. Бары тик өченче һәм дүртенче номерлы бакчаларда гына татар төркемнәре оешкан.

Балалар бакчаларында туган телдә белем һәм тәрбия бирү күрсәткече 48 ( кырык сигез ) процент тәшкил итә .

2015-2016нчы уку елы нәтиҗәләре буенча Азнакай районы милли мәгариф республика рейтингында 24 нче урынны били.

Безнең районның 80 (сиксән) процентын татарлар тәшкил итә, ә туган телдә белем алучылар саны егерме биш процент кына. Милли мәгариф алдында торган бу һәм башка мөһим мәсәләләрне хәл итү максатыннан Азнакай районында милли мәгарифне үстерү буенча төрле чараларны үз эченә алган эш планы төзелде. Бу план, яисә "юл картасы"ның нигезендә Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү Концепсиясе ята. Комплеслы «юл картасын» булдыру максатыннан милли белем бирү буенча директор урынбасарлары, мәктәпкәчә белем бирү җитәкчеләре, мәдәният, спорт, яшьләр, масса күләм информация чаралары җитәкчелеге вәкилләре, шулай ук туган телне, мәдәниятне саклау һәм үстерү буенча социокультур мәсәләләрне башкаручы төрле оешма вәкилләре бу эшкә тартылды. Гомуми эшнең нәтижәсе булып милли мәгариф системасы белән идарә итүне тагы да камилләштерү буенча төрле чараларны үз эченә алган план барлыкка килү тора. Азнакай муниципаль районы буенча милли мәгарифнең үсешен билгеләүче юл картасы 2016нчы елның егерме тугызынчы декабрендә Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланды.

**Ул дүрт бүлектән тора:**

1. **Милли мәгариф белән идарә итү системасының нәтиҗәлелеген күтәрү**
2. **Татар телендә белем бирү оешмалары челтәренең үсешен булдыру**
3. **Милли мәгариф эчтәлегенең камилләшүе**
4. **Милли мәгарифне тәэмин итү ресурсларының үсеше**

Беренче бүлек үз эченә Азнакай районында милли мәгарифнең торышына системалы анализ ясауга һәм бәяләүгә юнәлгән чараларны үз эченә ала. Бу татар телендә белем һәм тәрбия бирү учреждениеләренең эшчәнлеген, милли мәгариф мәсьәләләре буенча директорлар һәм директор урынбасарлары семинарлары, дәүләт телләрен мәктәпләрнең официаль сайтларында тигез күләмдә файдалануны мониторинглаштыру, "туган телдә белем бирү төркемнәрен һәм классларын ачу"ны мәктәп һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләүнең вариатив өлешенә кертү, Актаныш, Саба, Лениногорск, Бөгелмә, Мөслим районнарының милли мәгарифне үстерү буенча эш тәҗрибәләрен өйрәнү һәм башкалар.

Икенче бүлек милли белем бирү оешмалары, класс, төркемнәр челтәрен саклау һәм яңаларын ачу өчен шартлар тудыруны күз алдында тота. Яңа уку елыннан башлап дүрт ел эчендә Азнакай шәһәре мәктәпләрендә татар телендә белем бирү класслары ачу планлаштырыла. Авыл мәктәпләрендә исә татар телендә укытуны саклап калу. Шулай итеп, татар телендә укытуны 2018нче елга 36(утыз алты) процентка арттыру карала.

Юл картасында мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дә татар телендә белем бирү төркемнәрен үстерү, күз алдында тотыла. 2020нче елда ул 48 (кырык сигез)процент тәшкил итәчәк.

Өченче бүлек-милли мәгарифнең эчтәлеген камилләштерү. Бу өлкәдәге чаралар укучыларда туган телне өйрәнүгә карата булган мотивацияне үстерү һәм нәтиҗәлелекне күтәрү, туган тел һәм әдәбияты укытучыларының профессионал осталыгын, поликультур җәмгыятьтә шәхеснең толерант аңын һәм үз-үзен тотышын формалаштыру, туган төбәкнең тарихын һәм йолаларын өйрәнү, әңгәмә, конференция, бәйге, әдәби-музыкаль кичәләр, халык уеннары, милли –мәдәни бәйрәмнәрне оештыру һәм уздыру барышында, төрле халык вәкилләре арасында мәдәни-ара аралашуларны көйләүгә юнәлтелгән.

Милли мәгарифне ресурс ягыннан тәэмин итүнең үсеше педагогик кадрларны әзерләү, аларның квалификацияләрен үстерү, дәүләт телләрен өйрәнү кабинетларын заманча җиһазлар белән тулыландыру, яңа буын иллюстратив һәм күрсәтмә материаллар, мәктәп китапханәләренең фондын милли һәм төбәкне ойрәнү әдәбияты белән тулыландыру, татар класслары очен ”Школа России” системасы буенча региональ һәм федераль исемлектәге уку-методик комплектларын булдыруны тормышка ашыруны күз алдында тота. Милли мәгарифне үстерү буенча төзелгән чаралар планын тормышка ашыруда көтелгән нәтиҗәләр укучыларда туган телен, мәдәниятен, тарихын өйрәнүгә, татар телендә уку теләге буддыруга, милли мәгариф эчтәлегенең яңаруын, ресурс, методик, информацион яктан якlануына, милли мәгарифнең үсешен объектив һәм үтә күренмәле мониторинглаштыру системасында уңай динамика булдыруга нигезләнгән.

**Шулай итеп, 2017нче елда безнең алдыбызда түбәндәге бурычлар тора:**

1. **Мәктәпләрдә туган телдә белем алучы укучылар санын арттыру;**
2. **Балалар бакчаларында татар төркемнәре челтәрен киңәйтү, Актүбә бистәсендә татар телендә төркемнәр ачуга игътибарны юнәлдерү;**
3. **Милли мәктәпләр буларак Гимназия, Актүбә бистәсенең 3нче, Азнакай шәһәренең беренче мәктәпләренең мөмкинлекләрен тагын да үстерү.**

Шайдуллин М.З. : Обучение языку — планомерный, целенаправленный процесс развития познавательных способностей детей, усвоения ими системы элементарных знаний об окружающем и соответствующего словаря, формирования речевых умений и навыков. Основными формами обучения татарскому языку в дошкольных учреждениях являются: обучение в повседневной жизни и в непосредственно образовательной деятельности. Главной целью по обучению татарскому языку является формирование правильной устной речи детей. Развитие устной речи, овладение элементарными формами разговорной речи, формирование речевых навыков и умений не происходит стихийно, а под руководством воспитателя. Ребенок в повседневной жизни (во время прогулок, одевания, умывания, организованной игровой деятельности и в других типичных ситуациях) не обращает внимания на определенные языковые явления, речевые образцы и не следует им. Дети фиксируют свое внимание на них, которые становятся предметом его осознания. Образовательная деятельность помогает компенсировать дефицит общения родителей с ребенком.

Следует отметить, уважаемые приглашенные, на сегодняшний день татарский язык, наш родной язык, задвинут на второй план. Причем необоснованно. Именно по этой причине мы попали в зону критики. Действительно, необходимо вести работу и планомерную работу по внедрению татарского языка не только в образовательные учреждения. А и в нашу с Вами повседневную жизнь. Необходимо начать вести все совещания, планерки на татарском языке. Это отнюдь не в ущерб изучению русскому языку, все должно быть в равных долях. Так же как и татарин владеет русским языком, русский тоже должен знать татарский язык. Необходимо с детва прививать любовь к родному языку, но это не должно быть в принудительной форме. Необходимо, прежде всего кардинально изменить наше мышление и вести планомерную работу с директорами и заведующими детских садов. Они в свою очередь должны проработать все эти вопросы с родителями, я думаю, родители поймут Вас, если правильно донести информацию. Это неприемлемо, что наши дети не знают свой родной язык, свою культуру и традиции. Эльвира Йолдызовна, прошу Вас начать работу по активизации работы по внедрению в образовательные учреждения татарского языка, открывать татарские классы и грамотно вести работу с родителями.

Решили: Уделять особенное внимание преподаванию татарского языка в школах города и района, формированию речи ребенка, изучению обычаев татарского народа. - *Ахмадишина Л.М., Зарипова Э.Й.*

Открытие в детских садах татарских групп - *Зарипова Э.Й.*

2. Слушали «Основные направления государственной политики в области преподавания языков.

Выступила Абдуллина Дилярия Маратовна - ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова Академии наук РТ, автор учебников по татарской литературе, автор новой Конңепции преподавания татарского языка и литературы, кандидат филологических наук.

Информацию Абдуллиной Дилярии Маратовны принять к сведению.

3. Слушали «Гимназия шартларында укучыларда милли үзаң тәрбияләү».

Выступил Рахманов Альберт Магалимович - Член Общественного Совета, председатель Совета директоров школ.

Халыкның бүгенгесе, киләчәге, дөньякүләм тоткан урыны, һичшиксез, аның аң-белем дәрәҗәсенә, рухи-әхлакый үсешенә турыдан-туры бәйле. Шуңа күрә, яшь буында милли үзаң, рухи сәламәтлек, җан һәм тел камиллеге, киң һөнәри әзерлек, гадәти булмаган мәсьәләләрне хәл итү осталыгы тәрбияләү - белем бирү учреждениеләре алдында торган төп бурычлардан санала.

Азнакай шәһәре гимназиясе алдында торган иң әһәмиятле бурычлар да туган телебезне, тарихыбызны өйрәнү, яшь буында милли үзаң формалаштыру, иҗади, көндәшлеккә сәләтле, толерантлы, сыйфатлы белем алган заманча шәхесләр тәрбияләү. Бүгенге көндә төрле телләрне өйрәнүдә, шәхес тәрбияләүдә гимназия зур урын алып тора. Татар теле белән бер рәттән, гимназиядә инглиз, рус телен тирәнтен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Төрле телләрдә иркен аралаша торган укучылар тәрбияләү, бердәм дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырырга да ярдәм итә. Безнең күрсәткечләребезнең республика, район күрсәткечләреннән югары булуы шуны раслый.

Азнакай шәһәре гимназиясендә укучыларга милли тәрбия бирү берничә юнәлештә алып барыла. Бу юнәлешләргә түбәндәгеләр керә:

1. Тел өйрәтү.
2. Халыкның әдәбиятын, әдәбият аша мәдәниятен өйрәтү, гореф-гадәт, тарихына карата кызыксыну уяту.
3. Кызыксыну уятып кына калмыйча, класстан тыш чаралар ярдәмендә шул мохит, шул тирәлектә яшәү ихтыяҗы тудыру.

4. Хәзерге чор балаларын милли үзаңлы итү өчен, аларның ата-аналары белән һәм гаилә аша эш итү.

Әлеге эшләрне бер дәрәҗәдә алып бару һәм туктаусыз үстерү генә яхшы күрсәткечләргә, нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Тел дәресләрендә укучыларга туган телне, әдәбиятны тирәнтен өйрәтүгә, халкыбызның бай рухи мирасын пропогандалауга, балаларда милли үзаң, горурлык хисләре тәрбияләүгә, татар дөньясының иҗтимагый, сәяси, мәдәни тормышы белән якыннан һәм даими таныштырып баруга әһәмият бирәбез.

Бу укучыларыбызның республика күләмендә уздырылган бәйгеләрдә, фәнни-гамәли конференцияләрдә, олимпиадаларда уңышлы чыгыш ясаулары белән билгеләнә.

Балаларда милли үзаң үстерүдә дәрестән тыш үткәрелә торган чаралар да зур әһәмияткә ия. Укучылар һәм укытучылар район күләмендә, гимназиядә үткәрелгән бу чараларда актив катнашалар. Традиңион милли бәйрәмнәр белән бер рәттән, гимназиянең үз традиңияләренә әйләнгәннәре дә еш уздырыла. Боларга “Гимназистлар балы”, “Туган тел”, гаилә бәйрәмнәре, әдәби кунакханәләр керә. Алар барысы да халкыбызның күңел бизәкләрен киләчәк буынга җиткерүгә, балаларда милли үзаң тәрбияләүгә юнәлтелгән. Гимназиядә 100% татар балалары укуын исәпкә алсак, бу кирәкле һәм әһәмиятле эш.

Балаларның иҗади мөмкинлеген үстерү максатыннан, гимназиябездә “Яшь редактор”, “Сәхнә”, “Фольклор”, “Радиоүзәк” студияләре эшләп килә. Укучыларыбызның милли үзаңнары үскән саен, әйләнә – тирә тормыштагы вакыйгаларга карата үз фикерләрен әйтәсе килү теләге дә көчәя. Иҗат җимешләрен гимназия, шәһәр, республика күләмендә күрәселәре килә. Бу максатны тормышка ашыру өчен “Минем гимназиям” газетасы чыга башлады. Газетабыз укучыларыбыз өчен иҗат мәйданы булып тора.

Гимназиянең тышкы элемтәләр булдыру, социаль партнерлыкны җәелдерү өстендә алып барылган эшчәнлеге дә, укучыларда милли үзаң тәрбияләүгә уңай йогынты ясый. Азнакай районы “Ак калфак” хатын-кызлар җәмгыяте оешмасы белән тыгыз элемтәдә булу да очраклы хәл түгел. Беренчедән, гимназиянең татар теле укытучылары үзләре дә бу оешма әгъзалары, икенчедән, аларны бер үк максат берләштерә, ул татар халкының милли гореф-гадәтләрен саклау һәм шул гореф-гадәтләрнең кануны нигезендә балаларны тәрбияләүдән гыйбарәт. Гимназия кысаларында укучыларда милли рух һәм патриотик тәрбияне ныгытуга юнәлдерелгән чаралар, татарча көрәш түгәрәгенең эшләп килүе, татар орнаментлары белән чигү, гимназиядә гадәттәге звонок чыңының татар халык көйләренә

алыштырылуы бу хезмәттәшлекнең нәтиҗәсе булып тора. Һәр елны апрель аенда Таттелеком оешмасы хезмәткәрләре белән уздырыла торган Тукай көннәре дә иң матур бәйрәмнәребезнең берсе.

Яшь буынның бүген алган тәрбиясе – халкыбызның алдагы коне ул. Милли мәгарифне, татар телен саклау буенча гимназиядә зур эш алып барыла, киләчәктә дә күрсәткечләребезне яхшыртып, зур уңышларга ирешербез дип уйлыйбыз.

Информацию Рахманова Альберта Магалимовича – принять к сведению.

4. Слушали «Взаимодействие институтов гражданского общества по сохранению традиций».

Выступила Галиева Эльвира Сайлуновна - председатель общественной организации татарских женщин «Ак калфак», начальник организационного отдела районного Совета.

Җәмгыятебез үзгәрешләр чоры кичерә. Бигрәк тә яшь буынның рухи-әхлакый хәле борчый. Ә бит халкыбызның алдагы коне, киләчәк язмышы яшьләргә бүген нинди тәрбия бирү белән тыгыз бәйләнгән.

Бүгенге көндә яшь буынга дөрес тәрбия бирүдә халык педагогикасы хәзинәләреннән файдалану кирәклеге бигрәк тә үзен сиздерә, минемчә. Чөнки яшь буында милли үзаң формалаштыру һәм шуның аша үз туган телен, халкын сөюче, аның чын тарихын өйрәнергә омтылучы, үз милләтенең мәнфәгатьләре өчен янып-көеп йөрергә сәләтле шәхес тәрбияләүне халык педагогикасыннан башка күз алдына китерүе дә кыен. Димәк, яшь буынны тәрбияләүдә гаять зур роль уйнаган гореф-гадәтләрне, традицияләрне торгызу-яңарту чорында яшибез дисәк тә ялгышмабыз.

Шуңа күрә халыкнын торле яшьтэге катламнары белән бик күп төрле тәрбия чаралары үткәрәбез, тормышның барлык якларын искә алабыз. Районның ЗАГС бүлегендә “Димчеләр”, “Пар канатлар клублары” эш алып бара. Анда халык педагогикасы нигезләрен, бишек җырларын өйрәнү, гаилә бюджеты нигезләрен, баланы балалар бакчасына әзерләү, милли ашлар әзерләргә өйрәнү дәресләре бирелә, аерылышу дәрәҗәсенә җиткән гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтелә.

Районда яшәүче аналар исеменнән солдат бурычын үтәүче егетләребезгә хатлар җибәреп торабыз, изге теләкләребезне юллыйбыз. Сугыш һәм хезмәт ветераннары белән очрашулар үткәрәбез, үзебезнең рәхмәтебезне җиткерәбез, инвалид балаларга ярдәм оештырабыз.

Шулай ук, мәгариф идарәсе һәм укыту тәрбия учреңдениялары җитәкчеләренә уку йортларында кыңгырау авазын татар һәм башка ил телләрендәге классик музыка әсәрләре белән чиратлаштырып уйнатуны кертү тәкъдиме белән чыктык. Бу тәҗрибә балаларда мәрхәмәтлелек, җаваплылык хисләре уятыр, дөньяны аңларга ярдәм итәр иде.

Шулай ук балалар бакчаларында йокы сәгате Бишек җырларын көйләп башлау тәҗрибәсе дә кызганычка каршы кин таралыш алмады.

Бишек җырлары зур тәрбияви көчкә ия, баланың теле ачылуда, зиһенен уятуда иң тәэсирле тәрбия чарасы, дип саныйм мин аны. Әйе, тел балага бишектә үк – милли моң-җыр белән бергә сеңә, ныгый. Балалар бакчасында да бишек җырларын тыңлау дәвам иткәндә, баланың рухи үсеше дәвам итә, үз гаилә мохитендә алган тәрбия чаралары балага әни кочагыннан аерылуны йомшаграк кичерергә ярдәм итә, дип саныйм һәм әлбәттә инде тирән тәрбия алып үскән сабый үсә төшкәчтен дә яман юлга басудан, начар гадәтләрне үз итүдән ераграк булачак.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсе килә: халкыбызның телен, гореф-гадәтләрен, бәйрәм-йолаларын белеп үскән бала, киләчәктә илен, җирен һәм халкын ихлас яратучы, чын патриот булыр.

Барлык башлангычларыбыз да уңышлы тормышка ашсын, иң мөһиме милләтебезне, халкыбызны берләштерүгә, милли гореф гадәтләребезне гадәти тормышыбызга кайтаруга үзенең өлешен кертсен иде!

Мин яшимен татар илендә,
Сөйләшәмен татар телендә.
“Әттә”, “әннә”, “мәммәм” булган бит,
Иң беренче әйткән сүзем дә.
Миңа күчкән татар милләтенең
Тырышлыгы, моңы, аһәңе.
Гасырлардан гасырларга килгән
Матур, камил, көчле үз теле.
Менә шулдыр инде рух көче
Нәсел җебе аша бирелгән,
Гыйлемлелек, күңел сафлыгы,
Чын ярату туган илеңә.

Информацию Галиевой Эльвиры Сайлуновны – принять к сведению.

М.З. Шайдуллин: Спасибо вам за Вашу активную работ. Под Вашим руководством ведется работа по улучшению жизни женщин, семьи и детей; разработка предложений и помощь государству по разрешению наиболее острых проблем, касающихся женщин, в частности женской безработицы; охраны материнства и детства; поддержки многодетных семей;

повышение роли женщин в мировом экономическом и политическом процессах; консолидация татарской нации путем сохранения национальной семьи, сохранения и развития языка, обычаев.

Э.Й. Зарипова: Двери детских садов и школ всегда открыты. Учителя с большой ответственностью относятся по подготовке к урокам, поэтому считаю, что вы можете посетить наши уроки в любое время. Добро пожаловать!

Э.С. Галиева: Марсель Зуфаровтч! Считаю, необходимым распространить опыт по внедрению в детские сады колыбельных песен. На словах многие начали работать, но в действительности этого нет! Не должно это оставаться на теории, нужно работать в этом направлении активно. Ведь через колыбельные песни мы можем привить детям любовь к родителям, родному языку, и культуре. МБДОУ №6 в этом направлении ведет очень активную работу.

Э.Й. Зарипова: Действительно, это наше упущение. Для реализации данного проекта не нужны финансовые затраты, это все зависит исключительно от нас.

5. Слушали « Развитие чувашской национальной культуры в АМР».

Выступил Владимиров Олег Иванович - Председатель местного отделения Чувашской национально-культурной автономии.

На территории Азнакаевского района в настоящее время проживает более трехсот чувашей. В основном они проживают в г.Азнакаево и п.г.т Актюбинский. Местом компактного проживания является единственная чувашская деревня Якты-Куль. История этой деревни насчитывает более 90 лет и уходит своими корнями в село Суркино Альметьевского района. В свое время Якты-Куль была деревней, имеющая свой клуб, национальную чувашскую школу с обучением на родном языке. Сейчас школа закрылась, так как не осталось детей, и население деревни постарело.

Однако чуваши сохраняют свой быт, обычай, язык, культуру, традиции. Несомненно, проживание и тесные связи с татарским народом оказали свое влияние, поэтому и их традиции и национальные блюда, быт, язык, культура проникли в нашу чувашскую жизнь.

Таким образом, чуваши Азнакаевского района являются смешением двух культур: и чувашского, и татарского, при этом сохраняя и пропагандируя свои национальные чувашские традиции.

Уже на протяжении последних 10 лет ежегодно на праздник «Сабан Туй» выставляется экспозиция «Чувашский дом», где представляются книги, музыка, одежда, предметы быта с элементами чувашских узоров и орнаментов.

Традиционно участвуем на празднике «Чатыр-Тау Сабантуй», в других культурно-массовых мероприятиях, где выставляются также и национальные чувашские блюда и напитки.

Я, как представитель от чувашей Азнакаевского муниципального района, принимал участие на Всероссийском чувашском празднике «Уяв» в Нурлатском районе («Уяв» - это аналог татарского «Сабантуя»)

Постоянно поддерживаю связь с представителями Общества «Чувашская национальная автономия» и по мере возможностей участвую в мероприятиях.

В настоящее время в национально-культурном центре г. Азнакаево работает постоянно действующая экспозиция «Чувашский дом», где любой желающий может ознакомиться с бытом и культурой чувашей. В оформлении этой экспозиции принимали участие жители деревни Якты - Куль.

В 2017 году на смотре художественной самодеятельности района силами дома культуры села Учалле была представлена чувашская песня «Кай кай Ивана» в исполнении женской группы и номер вышел в финал смотра.

Такая работа является важным элементом для сохранения культуры, быта, языка, традиций чувашского народа, воспитание чувство гордости за свой народ и показатель того, как можно мирно, дружно уживаться в многонациональной семье российского народа, не теряя своей национальной идентичности.

Информацию Владимирова Олега Ивановича – принять к сведению.

6. Слушали «Выбор делегатов Съезда народов Татарстана».

Выступил Халиуллин Айдар Фандасович – руководитель аппарата районного Совета.

Уважаемые коллеги!

В соответствии с Указом Президента Республики Татарстан от 20.12.2016 № УП-1150 22 апреля 2017 года в Казани состоится Съезд народов Татарстана

Организационным комитетом по подготовке и проведению съезда утверждены квоты на выдвижение делегатов на Съезд от муниципальных образований республики, нашему району выделено 10.

В этой связи необходимо в срок до 1 апреля текущего года организовать работу по формированию делегации от муниципального района (городского округа).

При выдвижении делегатов на съезд рекомендовано придерживаться следующих подходов:

- делегация должна формироваться с учётом национального состава муниципального образования;

- необходимо обратить внимание на гендерный и возрастной состав

делегатов;

- состав делегации должен включать наиболее достойных представителей разных социальных групп (учителей, врачей, работников культуры, сельского хозяйства, промышленности и др.), руководителей этнокультурных организаций, ветеранов войны и труда, граждан, удостоенных государственных наград.

Рекомендовано избрание делегатов Съезда и утверждение состава делегации следует провести на расширенном заседании Общественного совета муниципального района (городского округа) с приглашением этнокультурных организаций. При рассмотрении вопроса о реализации Концепции государственной национальной политики в Республике Татарстан в разрезе муниципального образования.

Организационным комитетом по подготовке и проведению Съезда принято решение о направлении членов оргкомитета и республиканского актива на заседания общественных советов.

Координация в целом по республике за эту работу возложена на Департамент Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики. Разрешите огласить список делегатов.

1. Шайдуллин М.З. – Глава Азнакаевского муниципального района.

2. Гилязов Д.Р. – заместитель руководителя Исполнительного комитета по социальным вопросам Азнакаевского муниципального района.

3. Ахмадишина Л.М. – зам. председателя Общественного Совета Азнакаевского муниципального района.

4. Кротов В.А. – председатель ТОС №11.

5.Владимиров О.И. – председатель Совета ветеранов Учалиннского СП.

6.Хафизова Г.С. – член общественной организации «Ак калфак», начальник МКУ «Управление культуры».

7. Исмагилова Х. Х. – заместитель директора по культурно массовой работе НКЦ «Казань», председатель землячества Азнакаевского района в г. Казани.

8. Галиева Э.С. – председатель общественной организации «Ак калфак», начальник организационного отдела РС.

9. Шайхулов Ф.Ф. – директор – главный редактор филиала «Татмедиа» в г. Азнакаево, член Общественного Совета.

10. Каракылыч Ырмак – представитель турецкой диаспоры.

Прошу Вас принять и утвердить предложенный список членов делегатов.

Проголосовали «за» - все члены Общественного Совета, «против» - нет, «воздержались» - нет.

Приняли решение об утверждении предложенного списка делегатов.

7. Слушали «Решение оптимизационной комиссии Азнакаевской центральной районной больницы».

Выступил Шигапов Ильдар Фираилевич – главный врач ГАУЗ «Азнакаевская ЦРБ».

Уважаемый марсель Зуфарович! Приглашенные! До сих пор, пока финансовое положение Азнакаевской ЦРБ позволяло содержать сельские учреждения здравоохранения в рамках выделенных финансовых средств, в нарушение всех нормативов Российской Федерации, мы старались их сохранить в полном объеме, хотя во многих районах республики прошла оптимизация маломощных амбулаторий и ФАПов с населением менее 80 жителей.

К сожалению, экономический кризис, происходящий в мире, не обошел стороной и нас. Поэтому, при возрастающих расходах на коммунальные потребности в учреждениях здравоохранения, на содержание санитарного автотранспорта и т.д., нас вынуждают идти на «оптимизацию зданий, транспорта и даже штатов».

По итогам работы учреждений здравоохранения в 2016 г., финансовый дефицит по амбулаториям составил – 2 млн.руб., по ФАПам – 7,5 млн.руб.; итого – 9,7 млн.руб.

Рабочая группа по проведению оптимизационных мероприятии в Азнакаевской ЦРБ рассмотрела данный вопрос, и с учетом действующих нормативов и правил организации амбулаторий и ФАПов, сокращения обслуживаемого населения и отсутствия соответствующих требованиям санитарных норм и правил зданий в течение последних лет, вынесла решение об оптимизации Чалпинской амбулатории и 3-ех ФАПов.

В д.Якты Куль в настоящее время проживает 69 человек, уже несколько лет фельдшер соседней деревни Учалле обслуживает по выездному принципу 2-3 раза в неделю. Все экстренные вызовы в ночное время обслуживаются отделением скорой медицинской помощи Азнакаевской ЦРБ. В самой деревне здание ФАПа не соответствует санитарным нормам и правилам. Оно в аварийном состоянии.

В деревне Балан Буляк ФАП расположен на втором этаже не отапливаемого здания сельского клуба и занимает площадь 80 кв.м. До 2016 года помещение ФАПа отапливалось электрическим обогревателем. В зимнее время нет возможности создать нормальные условия, как для работы фельдшера, так и для пациентов. Во-первых, данное здание не находится на балансе ЦРБ, во-вторых, выделенное помещение под ФАП невозможно отапливать только электрическим обогревателем, т.к. это пожароопасно и температура помещения в зимнее время не нагревается выше +6 - +8$^0$. Число жителей данного населенного пункта достигает 119 человек. В деревне Балан Буляк на сегодняшний день нет медицинского работника. Медицинское обслуживание жителей возложено на заведующего Камышлинского ФАП Расстояние до деревни Балан Буляк напрямую по грунтовой дороге 5 км, через село Чалпы - 9 км.

Октябрь Булякский ФАП обслуживает 86 человек. Уже третий год жителям данного населенного пункта медицинская помощь оказывается

фельдшером соседнего Таллы Булякского ФАПа, который 2-3 раза в неделю выезжает на своем автотранспорте. В зимний период медработник обходит все дома, нуждающимся оказывает медицинскую помощь. Помещение, выделенное под ФАП в общественном здании, составляет 118,7 кв.м. (3 комнаты), отапливается инфракрасным обогревателем. В зимний период температура в этих комнатах так же не превышает + 10, +12$^0$С, что делает невозможным прием пациентов в помещении ФАПа. Данное здание не на балансе ЦРБ, и, соответственно, нельзя провести ремонтные работы и регулировать тепловой режим.

Исходя из вышеизложенного, оптимизационная комиссия ЦРБ в целях приведения к нормативным требованиям МЗ РФ предлагает оптимизировать вышеназванные учреждения с 2017 года.

Данное решение оптимизационной комиссии Азнакаевской ЦРБ необходимо заслушать на заседание Общественного совета Азнакаевского муниципального района до 1 марта 2017 г. и представить решение в МЗ РТ и Росздравнадзор по РТ.

Информацию Шигапова Ильдара Фираилевича принять к сведению.

*Предложения, дополнения и замечания.*

Выступил Нэфис хэзрэт.
Выступила Заляева Зиля Асхатовна – заведующая МБОУ №10 «Алтынчач».

*Решение заседания Общественного Совета:*

1. Уделять особое внимание преподаванию татарского языка в школах города и района, формированию речи ребенка, изучению обычаев татарского народа - *Ахмадишина Л.М., Зарипова Э.Й.*
2. Открытие в общеобразовательных учреждениях и в детских садах татарских групп и классов - *Зарипова Э.Й.*
3. Активизировать работу по распространению опыта работы и внедрению в детские сады колыбельных песен на тихом часе.
4. Утвердить предложенный список делегатов на Съезд народов Татарстана.

Председательствующий объявил расширенное заседание Общественного Совета закрытым.

Секретарь Э.С. Галиева